**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«28» 10 2022 ел Яр Чаллы №3304

«Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2022 елның 29 сентябрендәге 2874 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын актуальләштерү максатында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау хакында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчләрен югалту турында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары нигезендә, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» Башкарма комитетның 2022 елның 14 мартындагы 700 номерлы карарына таянып,

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2022 елның 29 сентябрендәге 2874 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын актуальләштерү максатында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау хакында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчләрен югалту турында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары нигезендә, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» Башкарма комитетның 2022 елның 14 мартындагы 700 номерлы карарына таянып».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны ТР Тукай муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.Н. Яббаров